**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«31» 03 2026 ел Яр Чаллы шәһәре № 1027

Тукай муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясен төзү турында

Тукай муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәлелегеn тикшереп тору максатында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында" 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законга, Башкарма комитет турында нигезләмәгә таянып, Тукай муниципаль районы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Баланс комиссиясен төзү турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 2 мартындагы 632 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясен төзергә.
3. Тукай муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясе нигезләмәсен әлеге карарга 1 кушымта нигезендә расларга.
4. Тукай муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясе составын әлеге карарга 2 кушымта нигезендә расларга.
5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Башкарма комитетның 2026 елның «1» 03 1027 номерлы карарына 1 кушымта

# БАЛАНС КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Тукай муниципаль районы баланс комиссиясенең (алга таба - баланс комиссиясе) максатларын, формалаштыру тәртибен, составын, функцияләрен һәм компетенциясен, эш тәртибен билгели.

1.2. Баланс комиссиясе даими эшләүче орган булып тора һәм Тукай муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең икътисадый хәлен өйрәнү һәм яхшырту, муниципаль унитар предприятиеләрне финанс яктан савыктыру буенча чаралар күрүне тәэмин итү максатында төзелә.

1.3. Комиссия комиссия рәисеннән, аның урынбасарыннан, секретареннән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

1.4. Комиссия утырышында эшчәнлекләренең төп күрсәткечләре начараю тенденциясендә булган предприятие директоры һәм бухгалтерының катнашуы мәҗбүри.

1.5. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган закон һәм башка норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең функцияләре

Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

- эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм финанс яктан савыктыру буенча үз вакытында чаралар күрү максатында, предприятиеләрнең һәм оешмаларның агымдагы җитештерү-хуҗалык эшчәнлеген, финанс-икътисадый торышын өйрәнү һәм бәяләү;
- предприятиеләрнең кризис хәле сәбәпләрен ачыклау;
- предприятие җитәкчесенең һөнәри компетентлыгы дәрәҗәсен бәяләү;
- җитештерү-хуҗалык һәм финанс эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатында, предприятиегә идарә итү системаларын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү;
- ведомство буйсынуындагы предприятиеләрне финанс яктан савыктыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү (үзгәртеп оештыру, хосусыйлаштыру, милек комплекслары буларак ликвидацияләү яки сату) һ.б.;
- предприятиеләрне финанс яктан савыктыру программаларын эшләү буенча карарлар кабул итү.

## 3. Эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышлары квартал саен, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан квартал саен бухгалтерлык хисабы төзелгәннән соң үткәрелә һәм, әгәр Комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

3.2. Комиссия карарлары утырышта катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышлары белән ачык яки ябык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Комиссия әгъзасы кабул ителгән карар белән килешмәсә, аның теләге буенча беркетмәдә аерым фикер чагыла. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

3.3. Чакырулар һәм предприятиеләр турында әзерләнгән документлар комиссия әгъзаларына аның утырышы көненә кадәр 7 көн кала җибәрелә.

3.5. Комиссия карары белән беркетмә комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

## 4. Баланс комиссиясе карарын кабул итү тәртибе

4.1. Җитәкченең хисабын тыңлап, тапшырылган материалларны карап, баланс комиссиясе аларның нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәттән файдалануның агымдагы финанс хәлен, нәтиҗәлелеген, шулай ук аларның җитәкчеләренең һөнәри компетенция дәрәҗәсен бәяли.

4.2. Унитар предприятиеләр җитәкчеләре баланс комиссиясе утырышларына оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлеген һәм әлеге оешмалар белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген тасвирлаучы барлык сорала торган документларны тапшыралар.

4.3. Баланс комиссиясе таләбе буенча унитар предприятиеләр, учреждениеләр җитәкчеләре кирәкле аңлатмаларны телдән яки язма рәвештә бирергә тиеш.

4.4. Баланс комиссиясе карарлары гамәлдәге законнар нигезендә рекомендация характерын йөртә, ә ревизия билгеләү яки аудиторлык тикшерүе, финанс-хуҗалык эшчәнлеге һәм идарә итүнең нәтиҗәлелеге турында хисапны раслау өлешендә мәҗбүри характерда була.

4.5. Баланс комиссиясе беркетмәсенең мәгълүмат бүлеген өч өлештән: кереш, аналитик һәм йомгаклау өлешләреннән төзү максатка ярашлы.

4.5.1. Кереш өлештә унитар предприятиеләрнең җитештерү-хуҗалык һәм финанс эшчәнлегенең төп характеристикалары, тулы исеме, урнашу урыны, кайсы тармакка каравы һ.б. чагылыш таба.

4.5.2. Аналитик өлештә финанс хисаплылыгын һәм башка документларны анализлау нәтиҗәләре китерелә, оешманың финанс хәленә бәя, тулаем идарә сыйфатына бәя бирелә.

4.5.3. Йомгаклау өлешендә муниципаль мөлкәттән файдалануның, предприятиеләрнең җитештерү-хуҗалык һәм финанс эшчәнлеге нәтиҗәлелеген

арттыру, предприятиеләр белән идарә итүне камилләштерү буенча тәкъдимнәр чагылыш таба, әгәр нигезләр булса, предприятиеләр документларын баланс комиссиясендә кабат карау сроклары билгеләнә.

4.6. Муниципаль мөлкәттән нәтиҗәсез файдалану фактлары ачыкланган, унитар предприятиеләрнең зыяннары артуга, банкротлык билгеләре барлыкка килүгә китергән җитештерү-хуҗалык һәм финанс эшчәнлеге нәтиҗәләре начарайган очракта, баланс комиссиясе муниципаль мөлкәтне тартып алу турында, унитар предприятие җитәкчесе белән хезмәт шартнамәсен законнарда билгеләнгән тәртиптә туктату турында тәкъдимнәр кертергә мөмкин.

4.7. Баланс комиссиясе беркетмәсенең йомгаклау өлеше унитар предприятие эшчәнлегенә бәяне үз эченә ала: канәгатьләнерлек яки канәгатьләнерлек түгел.

4.8. Предприятиеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм идарә итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләре буенча баланс комиссиясе предприятиеләр эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр һәм эштәге теге яки бу җитешсезлекләрне бетерү өчен күрелергә тиешле чаралар турында күрсәтмәләр бирә.

## 5. Предприятиеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә анализ ясау өчен документлар составы

Унитар предприятиеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә анализ түбәндәге документлар нигезендә үткәрелергә мөмкин:

- Еллык һәм квартал бухгалтерлык хисабы, аңа барлык кушымталар белән (узган финанс елы һәм агымдагы финанс елының хисап чорлары өчен);
- Еллык бухгалтерлык хисабына аңлатма язуы;
- Дебиторлык һәм кредиторлык бурычларының җентекле расшифровкасы;
- Салым инспекцияләре актлары, аудитор җаваплары һәм аудитор бәяләмәләре;
- Унитар предприятиеләрнең финанс елына финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары;
- Баланс комиссиясе карамагындагы башка документлар.

Башкарма комитетның 2026 елның «10» 03 1027
номерлы карарына 2 кушымта

# БАЛАНС КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

**Комиссия рәисе:**

- Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе;

**Комиссия әгъзалары:**

- Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары;

- Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү буенча урынбасары;

- Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

- Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе;

- Контроль-хисап палатасы рәисе;

- Тукай муниципаль районының икътисад бүлеге башлыгы;

**Комиссия секретаре:**

- Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече;

**Кызыксынган затлар (килешү буенча)**